ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.02.2025 с.Старое Дрожжаное № 55

2025 елга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының конкрет территорияләренә (авыл җирлекләренә) муниципаль гомуми белем бирү оешмаларын беркетү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 декабрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 9 статьясындагы 1 пунктының 6 пунктчасы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта нигезендә 2025 елга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының конкрет территорияләренә (авыл җирлекләренә) муниципаль гомуми белем бирү оешмаларын беркетергә.
2. Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 13 мартындагы 111 номерлы «2024 елга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының конкрет территорияләренә муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрен беркетү турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Чүпрәле муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов